КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 сентябрь г.Казань № 819

2021 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны;

2021 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмала-ры, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы

оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәтләр күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында» 2019 ел, 28 август, 717 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 сентябрь, 819 нчы
карары белән расланды

2021 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары
һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне
гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль
районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын
әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле
мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә
норматив чыгымнар

| Хезмәт күрсәтү исеме | 1 кешегә норматив чыгымнар, сум |
|---|---|
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 557,27 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 670,02 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 771,22 |
| Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 883,97 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 2 026,74 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 2 139,49 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 771,22 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 883,97 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 сентябрь, 819 нчы
карары белән расланды

2021 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәтләр күләмнәре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Саны, кеше |
|---|---|
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 20 246 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 757 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 47 238 |
| Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 765 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 44 541 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 664 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 22 945 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 856 |